МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.10.2022 Казан ш. № 17-122

Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче тарафыннан эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджеты кодексының $242^2$ статьясындагы 3 пункты икенче һәм өченче абзацлары нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны тапшыру тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
_05.10.2022___ № 17-122
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны тапшыру тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына (алга таба – Министрлык) эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны тапшыру кагыйдәләрен билгели.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 158 статьясындагы 3 пункты нигезендә, судта Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән чыгып эш иткән яки судта Татарстан Республикасы казнасы яисә Татарстан Республикасы бюджеты хисабына акча средстволарын түләтү турында дәгъвалар (гаризалар) буенча җавап тотучы сыйфатында судта чыккан Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүче (алга таба – баш бүлүче) Россия Федерациясе Бюджет кодексының $242^2$ статьясындагы 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан республикасы ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә, техник мөмкинлек булмаганда – баш бүлүче җитәкчесе яки аның вәкаләтлесе имзалаган кәгазь документ рәвешендә эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшыруга бурычлы.

3. Эшне судта тикшерү нәтиҗәләре турында, суд актына шикаять белдерүгә нигезләрнең булуы һәм суд актына шикаять белдерү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны баш бүлүче эш буенча кабул ителгән суд акты күчермәсе белән бергә тапшыра, суд акты тексты Россия Федерациясе Югары Судының, гомуми юрисдикциядәге судларның һәм арбитраж судларының “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылган очраклардан тыш.

4. Эшне апелляцион, кассацион яки күзәтчелек инстанцияләрендә тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүматларда беренче инстанция суды атамасы, шулай ук

суд актын кабул итү датасы һәм беренче инстанция судында эш номеры күрсәтелергә тиеш.